**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 17 октябрендәге 3573 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 23 сентябрендәге 3071 номерлы «2025 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерүен гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның чыгымнарын каплау максатыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерүен гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның чыгымнарын каплау максатыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) төгәлләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 23 сентябрендәге 3071 номерлы «2025 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерүен гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның чыгымнарын каплау максатыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләрнең хезмәтләре өчен түләүгә һәм (яки) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр төзелгән хезмәткәрләрнең хезмәтләре өчен түләүгә һәм (яки) түләүле хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр төзелгән белгечләрнең хезмәтләре өчен түләүгә, әмма

соратыла торган субсидиянең гомуми суммасыннан 50 проценттан артык булмаган чыгымнар»;

1.2. 6 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«- субсидия алучы, хезмәтләрдән файдаланучыларның ихтыяҗларын һәм аларның яшен исәпкә алып билгеләнә торган хезмәткәрләргә мохтаҗлыктан чыгып, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче профильле белеме булган яисә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү юнәлеше буенча һөнәри әзерлек курсларын узган, шулай ук балалар белән шөгыльләнүгә карата чикләүләре булмаган хезмәткәрләрнең һәм (яки) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр төзелгән хезмәткәрләрнең һәм (яки) түләүле хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр төзелгән белгечләрнең штат буенча җитәрлек булуын тәэмин итә»;

1.3. 12 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«6) хезмәтләрдән файдаланучыларның ихтыяҗларын һәм аларның яшен исәпкә алып билгеләнә торган хезмәткәрләргә мохтаҗлыктан чыгып, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче профильле белеме булган яисә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү юнәлеше буенча һөнәри әзерлек курсларын узган, шулай ук балалар белән шөгыльләнүгә карата чикләүләре булмаган хезмәткәрләрнең һәм (яки) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр төзелгән хезмәткәрләрнең һәм (яки) түләүле хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр төзелгән белгечләрнең штат буенча җитәрлек булуын раслый торган документларның күчермәләре»;

1.4. 12 пунктның 7 пунктчасындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләр яки белгечләр белән хезмәт килешүләре, һәм (яки) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр, һәм (яки) түләүле хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр»;

1.5. 33 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Роптр – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә  һәм (яки) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр төзелгән хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә һәм (яки) түләүле хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр төзелгән белгечләрнең хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар, сум/ай»;

1.6. Тәртипкә кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә редакцияләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 17 октябрендәге
3573 номерлы карарына
кушымта

**2025 елда сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерүен гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларның чыгымнарын каплауга субсидия күләмен исәпләү**

Оешманың тулы атамасы:_______________________________________________
_____________________________________________________________;
____________________________________________________________,
салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) _________________________,
төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) ______________________________________,
исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) ____________, исәп-хисап счеты_____________,
банк исеме ______________________, банкның идентификация коды ________
__________________, корреспондент счеты _____________________________.
Икътисади эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторы (ОКВЭД) буенча оешма эшчәнлеге төре _______________________________________

| № | Товар (эш башкару, хезмәт күрсәтү) атамасы | Үлчәү берәмлеге | Саны | Сумма | Документларны раслый торган нигезләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләрнең, шул исәптән тиешле чараларны оештыру һәм уздыру өчен кирәкле белгечләрнең хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар | | | | |
| *Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләр яки белгечләр белән төзелгән хезмәт килешүләре, һәм (яисә) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр, һәм (яисә) түләүле хезмәт күрсәтү килешүләре; эш вакытын исәпкә алу табельләре; хезмәт хакын исәпләү буенча исәп-хисап ведомостьлары; хезмәт хакын күчерү турында банктан түләү йөкләмәләре яисә өземтәләре; салым һәм иминият хисаплары (мәсәлән, иминият кертемнәре буенча исәп-хисаплар) | | | | | |
| 1.1 | | | | | |
| 1.2 | | | | | |
| **Бүлек буенча барлыгы** | | | | | |
| 2 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган, оешманың эшләвен тәэмин итү өчен кирәкле милекне карап тотуга чыгымнар | | | | |

| № | Товар (эш башкару, хезмәт күрсәтү) атамасы | Үлчәү берәмлеге | Саны | Сумма | Документларны раслый торган нигезләр |
|---|---|---|---|---|---|
| *Аренда шартнамәләре яисә милек таныклыгы; башкарылган эш/хезмәтләрнең счет-фактуралары һәм актлары; торак-коммуналь хезмәтләр, ремонт, клининг һәм сак өчен түләү буенча түләү документлары | | | | | |
| 2.1 | | | | | |
| 2.2 | | | | | |
| **Бүлек буенча барлыгы** | | | | | |
| 3 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерү эшчәнлеге турында халыкка мәгълүмат җиткерү белән бәйле, шул исәптән мәгълүмат материалларын эшләү, төрле коммуникация каналлары аша урнаштыру һәм таратуга бәйле чыгымнар | | | | |
| *Подрядчы оешмалар белән хезмәт күрсәтүгә килешүләр; башкарылган эшләрнең счет-фактуралары һәм актлары; хезмәтләр өчен түләү буенча түләү документлары | | | | | |
| 3.1 | | | | | |
| 3.2 | | | | | |
| **Бүлек буенча барлыгы** | | | | | |
| 4 | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларның социальләштерү эшчәнлеге алып барыла торган биналарны ремонтлау, санитар эшкәртү һәм җыештыру чыгымнарын үз эченә алган хуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар | | | | |
| *Башкаручылар белән килешүләр; башкарылган эш актлары; хезмәт күрсәтүләр өчен түләү һәм товарлар сатып алу буенча түләү документлары | | | | | |
| 4.1 | | | | | |
| 4.2 | | | | | |
| **Бүлек буенча барлыгы** | | | | | |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | |

*Күрсәтелгән чыгымнар төрләре буенча чыгымнарны раслау өчен оешма санап үтелгән документларны тапшырырга тиеш.

_______________________________________/_________/_______________________

[җитәкче вазифасы атамасы (булган очракта)]  (имза)  (имзаның аңлатмасы)

Баш бухгалтер /_________/_______________________

(булган очракта)  (имза)  (имзаның аңлатмасы)

Исәпләүләр 20___ елның «___» ___________ тикшерелде

_______________________________/_________ /___________________

(хезмәткәрнең вазифасы атамасы)  (имза)  (имзаның аңлатмасы)

20___ елның «___» ___________

________________________